ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СУГУШЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Центральная ул., дом 27, село Сугушла,
Лениногорский район, 423281



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СУГЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Центральный урамы, 27 нче йорт, Сугышлы
авылы, Лениногорский район, 423281

Тел.: (8-85595) 3-81-91, факс: (8-85595) 3-81-91, Sugush.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәреннән һәм кендезге бүлектә укучы студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту;
- торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Центральная урамы, 27 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тттатарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зиатдинова

ИНН 1625000408
КПП 164901001